# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Җир асты байлыклары турында"
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

__1 статья.__ "Җир асты байлыклары турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, N11-12), түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

"Җир асты байлыклары турында"

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Әлеге Закон Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, алардан файдалануга һәм аларны саклауга бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала.

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

__1 статья.__ Әлеге Законда кулланылучы төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Лицензия - Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең вәкаләтле органы бирә торган һәм биләүчесенә эшчәнлекнең аерым бер төрен аерым бер вакытка гамәлгә ашыру хокукын бирүче махсус рөхсәт ул.

Лицензияле килешү (шартнамә) - җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы арасында җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензиягә нигезләнеп төзелгән килешү ул.

Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы -

122

җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан махсус вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органы ул.

Җир асты байлыкларының дәүләт фонды - Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының кулланылучы кишәрлекләре һәм кулланылмаучы өлешләре ул.

Тау эшләре кишәрлеге - тирәнлеге һәм мәйданы буенча чикләнгән, объектның, ятманың яисә аның элементларының контурлары аша үтәдән-үтә узучы шартлы яссылыклар рәвешендә проекцияләнгән һәм өслектә (планда) махсус бүленү тамгалары - почмак нокталары белән билгеләнгән җир асты байлыклары кишәрлеге ул.

Ятма - җир өстендә яисә җир астында файдалы казылмаларның киңлекләре белән чикләнгән файдалы казылма тупланышы яисә тупланышларының җыелмасы ул.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү - җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (төбәк геологик өйрәнү, эзләүләр һәм бәяләү, разведкалау) процессының бер, шулай ук берничә стадиясен яисә этабын үз эченә алган җир асты байлыкларының геологик корылышы турында мәгълүмат алу ул.

Разведкалау - ятманы һәрьяклап характерлаучы һәм аны сәнәгати бәяләү өчен, файдалы казылмалар чыгаручы предприятиене проектлау һәм төзү өчен кирәкле белешмәләр алу максатларында үткәрелүче геологик эшләр комплексы ул.

Файдалы казылмалар чыгару (чыганакны эксплуатацияләү, җир асты байлыкларын эшкәртү) - техник чаралар ярдәмендә җир астыннан каты, сыек һәм газсыман файдалы казылмалар чыгару процесслары ул.

Җир асты байлыкларыннан файдалы казылмалар чыгаруга бәйсез рәвештә файдалану - рациональ эшкәртү тирәнлегенә кадәр файдалы казылмаларны ачу өчен перспективасыз булган җир асты байлыклары кишәрлекләрендә нефть, газ һәм башка матдәләр, материаллар саклау өчен, шул исәптән радиоактив, зарарлы һәм агулы матдәләрне, җитештерү калдыкларын күмү өчен, агым суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләр катнашкан суларны) агызып төшерү, су үткәргечләр һәм башка корылмалар төзү өчен файдалану йөзеннән, җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү ул.

Махсус сакланылучы геологик объект - фәнни яисә эстетик әһәмияткә ия булган һәм дәүләт тарафыннан сакланылучы уникаль яисә типик геологик объект ул.

Җир асты байлыклары бөтенлеген асылдан бозу - җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларның ятмаларын эксплуатацияләү барышында яисә файдалы казылмалар чыгару белән бәйсез рәвештә җир асты байлыкларыннан файдалану өчен җир асты

корылмалары төзегәндә тау токымнары массивларының тоташлыгын бозу ул.

Яраксыз өем - файдалы казылмалар ятмаларын ачык яисә җир астында килеш эшкәрткәндә барлыкка килүче буш токымнар яисә кондицион булмаган рудалар массасы ул.

Капкач токымнар - файдалы казылманы каплап һәм (яисә) аерып торучы,алып ташлау өчен билгеләнгән һәм матди җитештерү өлкәсендә нәтиҗәле файдалану өчен яраксыз токымнар ул.

Җир асты байлыкларын ярлыландыру - файдалы казылманы чыгару барышында аның сыйфатын югалту яисә аңа буш токымнар катыштыру һәм чыгарылучы запасларны тора-бара югалтулар белән бәйле кире кайтармаслык процессларга китерүче шартлар барлыкка килү аркасында файдалы компонент булуны киметү ул.

Бетәшкән җир асты байлыклары - объектив рәвештә һәм запаслардан нәтиҗәле файдалануга бәйсез килеш нәтиҗәлелеге кимегән, эшкәртүнең соңгы стадиясендә булган ятма яисә аның бер өлеше ул.

Санитар якланучан зоналарның запаслары - эре сулыкларның һәм агымсуларның, торак пунктларының, корылмаларның, авыл хуҗалыгы объектларының саклanучан зоналары, тыюлыклар, тарих, табигать һәм мәдәният ядкярләре чикләрендә урнашкан һәм ятмаларны эшкәртүнең махсус алымнарын куллану белән бәйле нефть һәм газ ятмаларының запаслары ул.

Артык суландырылган ятмалар (киңәрлекләр) - ятманы эксплуатацияләү чыгымнары шул ятмалардан чыгарылучы нефтьне сатудан килгән керемнәрдән артып китәрлек дәрәҗәдә суландырылган ятмалар.

Нефть ятмаларын эшкәртүнең нәтиҗәлелеген арттыру - югарырак технологик һәм техник-икътисадый күрсәткечләргә ирешүгә юнәлдерелгән геологик, технологик, техник, оештыру гамәлләре комплексын тормышка ашыру ул.

Нефть бирүчәнлекне арттыру ысуллары - катламнарның агымдагы һәм азакны нефть бирүчәнлеген, ягъни башлангыч баланс запасларының никадәре чыгарылган яисә ятмаларны эшкәрткәндә икътисадый рентабельлек чигенә кадәр мөмкин булган зурлыкны арттыруга юнәлдерелгән ысуллар ул.

Техноген ятмалар - җир эшләгәндә яисә файдалы казылмаларны тау токымнары массивыннан аерып алу нәтиҗәсендә һәм тау эшләренең, баетылучан, металлургия һәм башка җитештерүләрнең калдыклары сыйфатында бер җиргә туплау нәтиҗәсендә барлыкка килгән тау эшләнмәләрендә һәм сәнәгадә куллану өчен сан һәм сыйфат ягыннан яраклы минераль матдәләр җыелмасы ул.

Файдалы казылма - җир кабыгының матди җитештерү өлкәсендә нәтиҗәле файдаланылырга мөмкин булган табигый минераль катламы.

Минераль чимал - турыдан-туры файдалану яисә киләчәктә эшкәртү өчен җир астыннан алынган файдалы казылма.

Запаслар - геологик разведкалау (тау, бораулау, сынау) эшләре нәтиҗәләре буенча турыдан-туры исәпкә алынган һәм саналган файдалы казылма җыелмаларының күләме һәм микъдары.

Ресурслар - җир асты байлыкларын геологик, геофизик һәм геохимик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча исәпләнгән файдалы казылманың потенциаль җыелмасы күләме яисә микъдары.

Коммерциячел ачыш - җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән кишәрлектә җир асты байлыкларын киләчәктә эшкәртү максатында үз акчалары исәбеннән геологик өйрәнгәндә җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан, сәнәга әһәмиятенә ия файдалы казылма ятмасын ачу.

Геологик кишәрлек - тирәнлеге һәм мәйданы буенча чикләнгән, объект контуры аша текә узучы шартлы яссылыклар белән проекцияләнгән җир асты байлыкларының, ятмасының яисә аның элементларының геологик өйрәнү рөхсәт ителгән кысаларда җир әстендә (планда) махсус бүлү тамгалары - чик нокталары белән билгеләнгән кишәрлеге.

2 статья. Җир асты байлыклары

Җир асты байлыклары туфрак катламыннан астарак, ул булмаганда - җир еслегеннән, сулыклар һәм агымсулар төпләреннән астарак, геологик өйрәнерлек һәм үзләштерерлек тирәнлектә урнашкан җир кабыгының бер өлешен тәшкил итәләр.

3 статья. Җир асты байлыклары турындагы законнар

Җир асты байлыклары турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнәләр һәм әлеге Законнан, аның нигезендә кабул ителүче законнардан, бүтән төрле норматив-хокукый актлардан гыйбарәт булалар.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, файдалы казылмаларның кайбер төрләрен (углеводородларны, радиоактив рудаларны һәм минералларны) чыгаруга, шулай ук радиоактив, зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмүгә, агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәле) агызып чыгаруга бәйле мөнәсәбәтләр, җир асты байлыкларыннан файдалануның һәм аларны саклауның әлеге Законда билгеләнгән принципларын һәм хокукый нигезләрен үтәгән килеш, башка законнар белән дә җайга салынырга мөмкин.

Җирләрдән, елга-сулардан, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясыннан, атмосфера һавасыннан файдалануга бәйле һәм җир асты

байлыкларыннан файдаланганда барлыкка килүче мөнәсәбәтләр тиешле законнар белән җайга салына.

4 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану принциплары

Җир асты байлыкларыннан файдалану түбәндәге принциплар нигезендә башкарылырга тиеш:

җир асты байлыкларына дәүләт милке;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына ирешүнең һәм аны туктатуның хокукый нигезләренең җир асты байлыкларыннан барлык файдаланучылар өчен бердәм булуы;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукларын лицензия нигезендә бирү;

җир асты байлыкларыннан файдалану шартларын беркетүнең шартнамәчел характеры;

түләүле булуы;

җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле һәм һәрьяклап файдалану;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда бозылган табигать объектларын торгызу;

барлык төр эшләрнең иминлеген тәэмин итү.

5 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә закон чыгаруны җайга салу;

җир асты байлыклары турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору;

законнар нигезендә башка төрле вәкаләтләрне башкару.

6 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минераль чимал базасын торгызу һәм җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә агымдагы һәм перспектив дәүләт программаларын әзер-

ләү һәм гамәлгә ашыру;

түләү алуларны, шул исәптән гомум таралган файдалы казылмаларны чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр алуларны тәртипкә салу;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына ирешү өчен инвесторлар арасында конкурс уздыру турында карарлар кабул итү;

Татарстан Республикасы исеменнән концессион шартнамәләр һәм продукция бүлешү турындагы килешүләр төзү;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына ирешү өчен конкурс һәм аукцион уздыру тәртибен билгеләү;

дәүләт программалары кысаларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне финанслауны тәэмин итү;

файдалы казылмалар ятмаларының дәүләт резерв фондын барлыкка китерү;

гомум таралган файдалы казылмаларның исемлеген раслау;

законнар нигезендә башка төрле вәкаләтләр башкару.

<u>7 статья.</u> Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы компетенциясе

Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, торгызу һәм чыгару өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияләр бирү;

файдалы казылмаларны геологик өйрәнгәндә, чыгарганда, шулай ук файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланганда файдаланучылар белән шартнамәләр төзү;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләү ставкаларын исәпләп чыгару тәртибен билгеләү;

гомум таралган файдалы казылмаларны чыгару өчен җир асты байлыкларын бирү тәртибен билгеләү;

җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

сәнәгати эшкәртүгә бәйле булмаган хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларыннан файдалану тәртибен билгеләү;

файдалы казылмалар запасларының федераль дәүләт балансын төзегәндә катнашу;

минераль чималга кондицияләрне раслау;

җир асты байлыклары турындагы һәм файдалы казылмаларның разведкаланган запаслары турындагы геологик мәгълүматка дәүләт

экспертизасы үткәрү;

файдалы казылмалар запасларын баланстан төшереп калдыру;

җир асты байлыклары турындагы мәгълүматны җыю, саклау һәм системалаштыру;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен дәүләт тарафыннан теркәү;

файдалы казылмалар ятмаларының һәм аларны ачуның дәүләт кадастрын һәм файдалы казылмаларның дәүләт балансын төзү һәм алып бару;

файдалы казылмалар чыгару өчен һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләрен дәүләт исәбенә алу;

файдалы казылмалар запасларының федераль дәүләт балансын төзегәндә билгеләнгән тәртиптә катнашу;

дәүләт акчалары исәбеннән алынган геологик мәгълүмат белән эш итү;

геологик мәгълүматның федераль фондын алып баруда катнашу;

законнарда каралган бүтән төрле вәкаләтләр башкару.

8 статья. Җирле администрация компетенциясе

Җирле администрация компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының файдалы казылмалар чыгару тармагы үсеше буенча дәүләт программаларын район, шәһәр халкының социаль-икътисадый һәм экологик мәнфәгатьләрен үтәү өлешендә үз территориясендә гамәлгә ашыруда катнашу;

гомум таралган файдалы казылмалар чыгару хокукын бирү турындагы карарларны билгеләнгән тәртиптә кабул итү;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар чыгару һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану өчен республика милкендәге җир кишәрлекләрен җир турындагы законнар нигезендә бирү.

9 статья. Җирле үзидарә органнары компетенциясе

Җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны чыгару өчен һәм аларны чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен, шулай ук әлеге Законда каралган эшчәнлекнең башка төрләре өчен җирле үзидарә милкендәге җир кишәр-

лекләрен җир турындагы законнар нигезендә бирү;

Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

10 статья. Файдалы казылмаларны гомум таралганнарга кертү тәртибе

Файдалы казылмаларны гомум таралганнарга кертү җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан башкарыла.

## II бүлек. Җир асты байлыкларына милекчелек

11 статья. Җир асты байлыкларына милекчелек

Җир асты киңлеген дә кертеп, җир асты байлыклары һәм җир астындагы файдалы казылмалар Татарстан Республикасының дәүләт милке булалар һәм җир асты байлыкларының дәүләт фондын тәшкил итәләр.

Җир асты байлыкларына хосусый милек рөхсәт ителми.

Минераль чимал лицензия шартлары нигезендә дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә, хосусый милектә һәм бүтән милек рәвешләрендә булырга мөмкин.

12 статья. Файдалы казылма ятмаларының (җир асты байлыклары кишәрлекләренең) дәүләт резерв фонды

Минераль чималның стратегик һәм дефицит төрләре белән Татарстан Республикасының икътисадый иминлеген билгеләүче дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен файдалы казылмалар ятмаларының (җир асты байлыклары кишәрлекләренең) бер өлеше дәүләт резерв фондына кертелергә мөмкин. Дәүләт резерв фондына файдалы казылмаларның яңа гына ачылган яисә файдалануга тапшырылмаган ятмалары гына кертелергә мөмкин.

Файдалы казылмаларның ятмаларын (җир асты байлыклары кишәрлекләрен) дәүләт резерв фондына кертү тәртибе һәм алардан файдалану шартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## III бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалану

### 13 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар

Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар һәм юридик затлар әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм нигезләр буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучылар булырга мөмкин.

Әгәр законда эшчәнлекнең җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле төрләре белән шөгыльләнү өчен махсус рөхсәт (лицензия) таләп ителүе билгеләнгән булса, җир астыннан файдаланучының тиешле төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруга рөхсәте (лицензиясе) йә эшчәнлекнең җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле төрләрен гамәлгә ашыру хокукы булган махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән шартнамәләре булырга тиеш.

Эчү һәм дәвалану максатында кулланылучы җир асты суларын разведкалау өчен бары тик юридик затлар гына, ә радиоактив калдыкларны һәм агулы матдәләрне күмү өчен - бары тик дәүләт унитар предприятиеләре генә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар була алалар.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары җир асты байлыкларыннан файдаланучылар була алмыйлар.

Углеводород чималын чыгару барышында аерым бер, чикләнгән җир асты кишәрлегеннән файдаланганда җир астыннан файдаланучыга җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вакытлыча өлешчә өченче затларга биреп тору рөхсәт ителә.

### 14 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре

Җир асты байлыклары файдалануның түбәндәге төрләре өчен тапшырылалар:

геологик өйрәнү;

файдалы казылмалар чыгару;

җир асты байлыкларыннан файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалану;

махсус саклanылучы геологик объектлар барлыкка китерү;

минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекция материалларын җыю.

Җир асты байлыклары кишәрлеге бер үк вакытта берничә төр эшчәнлек өчен бирелергә мөмкин.

### 15 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары

Җир асты байлыклары файдалану өчен билгеле бер чорга яисә

чоры чикләнмичә бирелә.

Җир асты байлыклары файдалану өчен түбәндәгечә билгеле бер чорга биреләләр:

5 елга кадәр - геологик өйрәнү өчен;

20 елга кадәр - файдалы казылмалар чыгару өчен;

25 елга кадәр - геологик өйрәнү һәм соңыннан файдалы казылмалар чыгару өчен.

Углеводород чималын чыгару өчен җир асты байлыклары ятманы эшкәртү өчен кирәк булган чорга файдалануга бирелә, ул ятмаларны җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итәрлек итеп эшкәртүнең техник-икътисадый нигезләүләреннән чыгып билгеләнә.

Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда һәм махсус сакланылучы геологик объектлар барлыкка китерү өчен җир асты байлыклары чикләмәгән чорга файдалануга тапшырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия биргән көннән исәпләнә башлый.

Җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану чоры тәмамланганчы кимендә бер ел алдан биргән гаризасы буенча, лицензияле килешү шартларын үтәгән килеш, әлеге статьяның икенче өлешендә билгеләнгән чор кысаларында озайтылырга мөмкин.

Файдалану чорын озайту әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Лицензия чорын озайтудан нигезсез баш тарту очрагында аның хуҗасы баш тартуга карата административ яисә суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

16 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы барлыкка килү нигезләре

Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның әлеге хокукы түбәндәге нигезләрдә барлыкка килә:

конкурс, аукцион яисә турыдан-туры сөйләшүләр һәм (яисә) үз акчалары исәбенә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкарган җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ятмалар ачылу фактын билгеләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары;

радиоактив, зарарлы, агулы матдәләрне һәм житештерү калдыкларын күмү максатларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукларының күчүе;

гомум таралган файдалы казылмаларны чыгару хокукын бирү турында дәүләт идарәсенең җирле органы карары.

17 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануга карата төп таләпләр

Җир асты байлыкларыннан файдалануга карата төп таләпләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

җир асты байлыкларын файдалануга тапшыруның әлеге Законда билгеләнгән нигезләрен һәм тәртибен үтәүдән;

җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнүләрнең тулылыгын һәм файдалы казылмаларның җир куеныннан чыгарылучы, анда калдырылучы һәм бетерелүче запасларын төгәл исәпкә алуны тәэмин итүдән;

барлык чыгарылучы чималны комплекслы куллануны тәэмин итүдән;

файдалы казылмаларны эшкәртүнең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең башка төрләрен башкаруның расланган технологик схемаларын һәм проектларын үтәүдән;

тау эшләрен алып баруның хәвефсезлек кагыйдәләрен үтәүдән;

табигатьне саклау һәм табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану таләпләрен үтәүдән;

тау эшләре предприятиеләрен, эшләнмәләрен, скважиналарны һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын консервацияләү һәм ябу тәртибен үтәүдән;

җир асты байлыкларын өйрәнү һәм сәнәгати эшкәртү белән бәйле эшләрне башкарганда аны пычратмый калудан;

законнардан килеп чыгучы бүтән төрле таләпләрдән.

18 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының төп хокуклары

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәге хокукларга ия була:

үзенә тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлеген, лицензиядә билгеләнгән файдалану төренә туры килерлек итеп, эшкуарлык эшчәнлегенең сайланган рәвеше максатларында файдалану;

минераль чималны һәм үз эшчәнлегенең бүтән нәтиҗәләрен лицензия һәм лицензияле килешү нигезендә куллану;

лицензиядә башкасы билгеләнмәгән булса, тау эшләре калдыкларын һәм аларга бәйле эшкәртү производстволарының калдыкларын куллану;

тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлек чикләрендә файда-

лы казылмалар ятмаларының мәйданнарында төзелеш алып баруны чикләү;

җир асты байлыклары чыгару өчен бирелгән кишәрлек чикләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне өстәмә рөхсәтләрсез башкару;

лицензиянең һәм лицензияле килешүнең гамәлдә булу вакытын озайту турындагы үтенечнамә белән мөрәҗәгать итү;

әгәр җир асты байлыкларыннан файдалану лицензия шартларын, лицензияле килешүне һәм законнарны үтәгән килеш башкарылса, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтканда башка затлар белән чагыштырганда өстенлектән файдалану;

элеккеге шартларда җир асты байлыкларыннан файдалануга комачауларлык гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, лицензия һәм лицензияле килешү шартларын кабат карап чыгу буенча лицензия биргән органга мөрәҗәгать итү;

кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга бәйле рәвештә яисә җир асты байлыкларыннан файдалануны туктатканда, әгәр бу хәлләр җир асты байлыкларыннан файдаланучы гаебе белән булмаса, предприятиене консервацияләү һәм ябу чыгымнарын түләттерү.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы әлеге Законнан килеп чыгучы башка төрле хокукларга да ия булырга мөмкин.

<u>19 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдаланучының төп бурычлары

Җир асты байлыкларыннан файдаланучының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

лицензиядә һәм лицензияле килешүдә билгеләнгән шартларны үтәүдән;

җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне тулысынча һәм вакытында кертүдән;

җир асты байлыкларын саклауны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны регламентлаучы стандартларны, нормаларны, кагыйдәләрне һәм таләпләрне үтәүдән;

тау эшләренең техник проектлары, планнары һәм аларны үстерү схемалары таләпләрен үтәүдән, файдалы казылмаларның нормадан тыш азаюын, ярлылануын һәм аларны сайлап алып кына эшкәртүне булдырмаудан;

геологик өйрәнү буенча тәкъдим ителүче эшләрне, эшкәртүләрне камилләштерү гамәлләрен, нефть бирүчәнлекне арттыруның һәм скважиналарны стимуляцияләүнең яңа ысулларын куллану программаларын, киләчәк елларга нефть чыгару күләмнәрен җир асты байлыкларыннан нефть һәм газ ятмаларын разведкалау һәм эшкәртү

өчен файдалану мәсьәләләре буенча республика комиссиясендә технологик схема яисә автор күзәтчелеге нигезендә ел саен раслаудан;

нефтьне максималь дәрәҗәдә алуның технологик һәм техник гамәлләре комплексын тормышка ашырудан, нефть бирүчәнлекне арттыруның икенчел һәм өченчел ысулларын кулланудан, эшкәртүне интенсификацияләүнең нәтиҗәле ысулларын гамәлгә кертүдән;

өстәмә рәвештә чыгарылган нефть күләмнәрен исәпкә алып барудан;

геологик, маркшейдерлык һәм эшләрне алып бару технологиясе белән каралган бүтән документацияне алып барудан һәм аның сакланышын тәэмин итүдән;

геологик мәгълүматны, шул исәптән үз акчалары исәбеннән алынганын да, Татарстан Республикасының Геологик мәгълүмат фондына тапшырудан;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне алып бару зонасында атмосфера һавасын, җирләрне, урманнарны, елга-суларны, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклау турындагы законнарның таләпләрен үтәүдән;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда бозылган җир җишәрлекләрен һәм башка табигать объектларын киләчәктә файдаланырга яраклы халәткә китерүдән;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда табылган кыйммәтле компонентлар (затлы металлар һәм башка минераллар) булу турындагы мәгълүматны лицензия биргән органга тапшырудан;

тау эшләре һәм шартлату эшләрен хәвефсез алып барудан;

тау эшләнмәләрен һәм бораулау скважиналарын җир асты байлыкларыннан файдалану тәмамлангач юкка чыгарудан;

җир асты байлыкларын соңыннан эшкәрткәндә һәм (яисә) башка төрле хуҗалык максатларында кулланырга мөмкин булган разведкаланган тау эшләнмәләренең һәм бораулау скважиналарының сакланышын тәэмин итүдән;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең тыюлыклар, табигать, тарих һәм мәдәният ядкярләре халәтенә зарарлы йогынтысын булдырмый калудан;

техноген калдыкларны зарарсызландыру һәм аларны файдалы эшкә тоту эшләрен үтәүдән;

лицензиянең гамәлдә булу вакыты узгач йә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылганда тау эшләре предприятиеләрен һәм җир асты корылмаларын юкка чыгарудан яисә консервацияләүдән;

законнарда каралган башка төрле вазыйфалардан.

184

20 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануны чикләү һәм тыю

Әгәр җир асты байлыкларының кайбер кишәрлекләреннән файдалану кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янарлык, хуҗалык объектларына яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерерлек булса, мондый файдалану Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

21 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукларын рәсмиләштерү

Җир асты байлыкларын файдалануга тапшыру әлеге Законда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә бирелүче лицензия рәвешендәге махсус рөхсәт белән рәсмиләштерелә.

Җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы арасында төзелүче лицензияле килешүдә (шартнамәдә) билгеләнә.

Татарстан Республикасының ирекле икътисадый зоналары территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Татарстан Республикасы законнарында каралган нигездә һәм шартларда алынырга мөмкин.

22 статья. Файдалануга тапшырылучы җир асты байлыклары кишәрлекләре

Лицензия нигезендә җир асты байлыклары кишәрлеге геологик эшләр һәм (яисә) тау эшләре өчен бүлеп бирелгән өлешләр рәвешендә тапшырыла.

23 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен тапшыру

Җир асты байлыклары кишәрлекләренең бөтенлеген асылда бозмыйча гына җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы карары буенча тау эшләре өчен геологик бүлеп бирелгән өлеш рәвешендә тапшырыла.

Геологик бүлеп бирелгән өлешне тапшырганда җир асты байлыкларын геологик өйрәнү башкарылачак чикләрдә кишәрлекнең мәйданы һәм тирәнлеге билгеләнә.

Җир асты байлыкларының геологик бүлеп бирелгән өлеш чик-

125

ләрендәге бер үк кишәрлегә бер үк төрле файдалы казылманы геологик өйрәнү өчен берничә затка бирелмәскә тиеш.

24 статья. Җир асты байлыкларын файдалы казылмаларны чыгару, файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану һәм махсус сакланылучы геологик объектлар булдыру өчен тапшыру

Файдалы казылмаларны чыгару өчен, файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану өчен, шулай ук махсус сакланылучы геологик объектлар булдыру өчен җир асты байлыклары кишәрлеге файдалы казылмаларны чыгару өчен бүлеп бирелгән өлеш рәвешендә тапшырыла.

Тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлекнең чикләрен билгеләгәндә файдалы казылмалар ятмаларының яссылык контурлары, җир асты корылмаларын төзү өчен билгеләнгән контурлар, тау эшләрен һәм шартлату эшләрен хәвефсез алып бару чикләре, тау токымнары хәрәкәте зоналары, тау эшләнмәләрен зарарлы йогынтыдан саклау зоналары, табигать объектлары, биналар һәм корылмалар астындагы саклануы бөтенлекләрнең контурлары, бортларның, карьерларның һәм киселешләрнең таралышлары һәм җир асты байлыклары халәтенә, җир өслеге халәтенә йогынты ясаучы башка факторлар исәпкә алыналар.

Тау эшләре өчен бүлеп бирелгән өлешнең чикләре файдалы казылма ятмаларын геологик өйрәнү материаллары буенча тау эшләре өчен бүлеп бирелгән өлеш турындагы акт һәм мондый өлешнең төгәлләштерелгән чикләрен билгеләүче бүтән төрле документлар рәвешендә рәсмиләштереләләр, алары исә актка кушымта итеп биреләләр.

Тау эшләре өчен кишәрлек алган җир асты байлыкларыннан файдаланучы бирелгән лицензия нигезендә шул кишәрлек чикләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына һичшиксез ия була.

25 статья. Тау эшләре өчен бүлеп бирелгән өлешне тапшыру тәртибе

Файдалы казылмалар чыгару өчен бүлеп бирелгән өлеш файдалы казылмалар запасларын раслаганнан соң билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Гомумтаралган файдалы казылмалардан гайре, бүтән барлык файдалы казылмаларны чыгару өчен тау кишәрлеге җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясе һәм җир асты байлыкла-

ры кишәрлекләрен сәнәгати үзләштерүнең расланган проекты булганда, кызыксынучы зат үтенече нигезендә тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органы тарафыннан бирелә. Тау эшләре кишәрлеге бирүдән баш тартуга карата лицензия хуҗасы тау эшләрен күзәтүнең югарырак дәүләт органына йә судка шикаять белдерергә мөмкин.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокуклары әлеге Законда билгеләнгән очракларда күчкәндә, тау кишәрлеге җир асты байлыкларыннан яңа файдаланучы исеменә рәсмиләштерелергә тиеш.

<u>26 статья.</u> Зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмү, агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләләрен) агызып чыгару

Җир асты байлыкларын әлеге статьяда билгеләнгән максатлар өчен файдалануга тапшыру әлеге Законның 87 статьясында билгеләнгән таләпне үтәгән килеш алардан кабат файдалану мөмкинлеге булмаганда гамәлгә ашырыла.

<u>27 статья.</u> Радиоактив матдәләрне һәм калдыкларны күмү

Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан гайре, радиоактив матдәләрне һәм калдыкларны Татарстан Республикасы территориясендә күмү рөхсәт ителми.

<u>28 статья.</u> Гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару хокукын бирү

Гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару хокукын бирү җирле администрацияләр тарафыннан башкарыла һәм җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы билгеләгән тәртип нигезендә үткәрелә.

<u>29 статья.</u> Гомумтаралган файдалы казылмаларны җир кишәрлекләре милекчеләре һәм биләүчеләре тарафыннан чыгару

Җир кишәрлекләре милекчеләре, биләүчеләре шушы кишәрлекләр чикләрендә, шартлату эшләрен кулланмыйча гына, дәүләт балансында саналмаган гомумтаралган файдалы казылмаларны үзләре теләгәнчә чыгарырга һәм шәхси ихтыяҗлары өчен биш метр тирәнлеккә кадәр җир асты корылмалары төзергә, шулай ук үзәкләштерелгән су тәэминаты чыганагы булмаган беренче сулы горизонтка

кадәр тирәнлектә көнкүреш коелары казырга һәм эксплуатацияләргә хокуклы.

30 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының күчүе

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы хокук дәвамчылыгы тәртибендә генә граждан законнары нигезендә күчәргә мөмкин.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы яңа юридик зат барлыкка килгәндә күчәргә мөмкин, җир астыннан файдаланучы юридик зат аның гамәлгә куючысы булса, бу хокук аңа бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә лицензия нигезендә махсус рәвештә эшчәнлекне дәвам итү өчен күчәргә мөмкин, әлеге очракта юридик затның законнар нигезендә барлыкка килүе һәм җир астыннан файдаланучы элеккеге юридик затның яңа барлыкка килгән юридик зат устав капиталындагы өлеше хокуклар күчү мизгеленә устав капиталының гомуми суммасының яртысыннан да ким булмавы шарт.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының продукцияне бүлешү турындагы килешү нигезендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектына күчүе "Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә башкарыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкәндә лицензия кабат рәсмиләштерелергә тиеш.

31 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату нигезләре

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы түбәндәге очракларда туктатыла:

әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалануны озайтуны сорап гариза бирмәгән булса, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясенең гамәлдә булу чоры тәмамланганда;

җир асты байлыкларыннан файдаланучы файдалану хокукыннан баш тартканда;

лицензияле килешүдә каралган шарт килеп туганда, бу шарт барлыкка килүгә файдалану хокукы туктатыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

җир асты байлыкларыннан файдалануның тәкъдим ителгән кишәрлегеннән лицензиядә билгеләнгән вакыт эчендә файдаланмаганда;

лицензиянең һәм лицензия килешүенең мөһим шартларын җир

асты байлыкларыннан файдаланучы даими бозганда;

җир асты байлыкларыннан куелган максатларда файдаланмаганда;

җир асты байлыклары файдалануга тапшырылган оешма яисә хуҗалык эшчәнлегенең бүтән субъекты бетерелгәндә;

кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, әгәр алар җир асты байлыкларыннан файдаланучы гаебе белән килеп чыкмаса.

32 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануны туктату тәртибе

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы әлеге Законның 31 статьясындагы беренче өлешендә һәм икенче өлешенең 2,4 абзацларында каралган нигезләрдә җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан туктатыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы әлеге Законның 31 статьясындагы икенче өлешнең 3 абзацында каралган нигезләрдә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануны килештерүче органнарның берәрсе тәкъдиме буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан туктатыла.

Әлеге Законның 31 статьясындагы икенче өлешнең 5 абзацында билгеләнгән нигезләр булганда, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы законнар нигезендә төзелгән ликвидация комиссиясе карары буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан туктатыла.

Әлеге Законның 31 статьясындагы икенче өлешнең 6 абзацындагы нигезләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы компетентлы орган бу турыда карар кабул иткәннән соң турыдан-туры туктатыла, әгәр предприятиенең эшчәнлеген туктатып тору сәбәпләре үз көчендә калган булса, соңыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органына хәбәр ителә.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензияне юкка чыгару юлы белән башкарыла, бу турыда җир асты байлыкларыннан файдаланучыга хәбәр ителә.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату тәртибе җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

33 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору нигезләре

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору нигезләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

җир асты байлыкларыннан файдалануның лицензиядә һәм лицензия килешүендә каралган шартларын даими рәвештә бозудан;

җир асты байлыкларыннан һәм әйләнә-тирә табигать мохитеннән нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау таләпләрен даими рәвештә бозудан;

аяныч хәлләр килеп чыгудан.

34 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору тәртибе

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензия биргән органның үз инициативасы буенча, шулай ук дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген башкаручы органнар тәкъдиме буенча да шушы лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында лицензия биргән орган тарафыннан карар чыгарылу юлы белән әлеге Законда каралган нигезләрдә туктатып торыла.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы карар, дәлилләнгән нигезләве белән бергә, кабул ителгәннән соң өч көн эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга һәм дәүләт салым хезмәте органнарына җибәрелә.

35 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын яңарту

Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турындагы гариза белән мөрәҗәгать итмәгән булса, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алардан файдалануны туктатып торуга китергән хәлләр бетерелгәннән соң яңартыла.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуны тәкъдим иткән орган тәкъдиме буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын яңартырга рөхсәт биргәннән соң җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясе яңартылган дип санала.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын яңарту турындагы карар өч көн эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга һәм дәүләт салым хезмәте органнарына җибәрелә.

## IV бүлек. Лицензияләүнең дәүләт системасы

36 статья. Лицензияләүнең дәүләт системасы

Лицензияләүнең дәүләт системасы - җир асты байлыкларыннан файдаланучының Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясен мәҗбүри алуының бердәм тәртибе ул, моңа җир асты байлыкларыннан файдалану хокукларын бирүнең әлеге Законда билгеләнгән нигезләре, лицензияне бирү һәм теркәү тәртибе, җир асты байлыкларыннан файдалану төрен исәпкә алып, лицензиянең һәм лицензияле килешүнең (шартнамәсенең) эчтәлегенә карата бердәм таләпләр, шулай ук лицензияләр бирүче һәм кабаттан рәсмиләштерүче дәүләт органнары һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы белән шартларны килештерү һәм лицензияле килешүләрне төзү керә.

37 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензияләренең төрләре

Эшчәнлек төре нигезендә бирелүче лицензияләр түбәндәге хокукларны таныкларга мөмкин:

җир астын геологик өйрәнү;

файдалы казылмалар чыгару;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану;

махсус саклланылучы геологик объектлар барлыкка китерү;

минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекция материалларын җыю.

Бирелүче вәкаләтләрнең күләменә карап, лицензияләр аерым һәм бер үк вакытта башкару төрләренә бүленәләр. Бер үк вакытта башкару лицензияләре җир асты байлыкларыннан файдалануның берничә төрен башкару хокукы өчен биреләләр.

Геологик өйрәнү хокукы лицензиясе аның хуҗасына геологик бүлеп бирелгән өлеш чикләрендә файдалы казылмаларны чыгару лицензиясе алганда өстенлекле хокук бирә.

38 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензияләрен рәсмиләштерү, бирү һәм теркәү тәртибе

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензияләрен җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы бирә һәм терки.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензияләрен,

шул исәптән продукцияне бүлешү турындагы килешүләр һәм концессион шартнамәләр нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен бирелүче лицензияләрне рәсмиләштерү, бирү һәм теркәү тәртибе, шулай ук аларның гамәлдә булуын туктатып тору һәм аларны юкка чыгару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

39 статья. Турыдан-туры сөйләшүләр тәртибендә лицензияләр бирү

Турыдан-туры сөйләшүләр тәртибендә лицензияләр түбәндәге очракларда бирелә:

җир асты байлыкларының элегрәк бирелгән кишәрлекләреннән файдаланучы гамәлдәге оешмаларга, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтканда да;

гомум таралган файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәртү өчен;

радиоактив, зарарлы , агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмү өчен, агым суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәлеләрен) агызып чыгару өчен;

минералогик, палеонтологик һәм башка коллекция материалларын җыю өчен;

махсус саклanылучы геологик объектларны оештыру өчен.

40 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда гайре монополия таләпләре

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, шулай ук теләсә нинди хуҗалык итүче субъектларның, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның түбәндәгеләргә юнәлдерелгән гамәлләре тыела һәм билгеләнгән тәртиптә хокукка яраксыз дип танышa:

шушы конкурс яисә аукцион шартларына карамастан, әлеге Закон нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына ирешергә теләгән юридик затларның һәм гражданнарның конкурста яисә аукционда катнашуын чикләүгә;

конкурста яисә аукционда җиңеп чыкканнарга лицензия бирүдән баш тартуга;

хуҗалык итүче субъектлар белән ярышучы һәм җир асты байлыкларыннан файдалануда алда баручы оешмалар төзүче җир асты байлыкларыннан файдаланучыларны дискриминацияләүгә;

транспорт һәм инфраструктура объектларына керүгә рөхсәт биргәндә җир асты байлыкларыннан файдаланучыларны дискриминацияләүгә;

әлеге Законда каралган очраклардан гайре, конкурсларны һәм аукционнарны турыдан-туры сөйләшүләр белән алмаштыруга.

41 статья. Конкурста яисә аукционда катнашуга кертүдән баш тарту нигезләре

Конкурста яисә аукционда катнашуга кертүдән баш тарту нигезләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

конкурсның яисә аукционның шартларын бозган килеш үтенечнамә бирүдән;

җир асты байлыкларының лицензияләнгән кишәрлегөн үзләштерү һәм файдалы казылмалар чыгару эшләрен хәвефсез алып бару өчен кирәкле финанс һәм техник ресурсларның барлыгы яисә алынуы турындагы белешмәләрне үтенеч бирүченең китереп бирмәвеннән;

үтенеч бирүченең үзе хакында белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирүеннән;

конкурста яисә аукционда катнашкан өчен бер мәртәбәлек кертемне түләмәүдән;

әлеге үтенеч бирүчегә лицензия бирелгән очракта гайре монополия таләпләре үтәлмәүдән.

42 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен бирелүче лицензиянең эчтәлеге

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен бирелүче лицензиядә түбәндәгеләр булырга тиеш:

теркәлү номеры;

лицензия бирүче орган исеме;

лицензия хуҗасы турындагы белешмәләр;

җир асты байлыкларыннан файдалану төрен күрсәтү;

файдалануга тапшырылучы җир асты байлыклары кишәрлегенең яссылык чикләрен күрсәтү;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр алып бару өчен бүлеп бирелүче җир кишәрлеге чикләрен күрсәтү;

файдалы казылма чыгаруның рөхсәт ителгән (максималь-минималь) күләме;

реализацияләнүче минераль чималның базар бәяләрен һәм аны куллану күләмнәрен үзгәрткәндә лицензия шартларын кабат карау тәртибе һәм вакытлары;

чыгарылган файдалы казылманы җир асты байлыкларыннан файдаланучы белән Татарстан Республикасы арасында бүлешү тәртибе, шул исәптән, продукцияне бүлешү турындагы килешү шартларында җир асты байлыкларыннан файдаланганда да.

143

эшләрне башлау вакыты (ике елдан артмаска тиеш);

лицензиянең гамәлдә булуын туктатырлык йә туктатып торырлык шартлар.

43 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкәндә бирелгән лицензияне кабат рәсмиләштерү

Лицензия җир асты байлыкларыннан файдаланучы гаризасы буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан кабат рәсмиләштерелә.

Лицензияне кабат рәсмиләштерү әлеге Законның лицензияне биргәндә аны рәсмиләштерүгә һәм теркәүгә карата таләпләре нигезендә башкарыла.

Әлеге статьяда каралган барлык очракларда җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензия белән рәсмиләштерелә, ул юридик затлар дәүләт тарафыннан теркәлгәннән соң (кабат теркәлгәннән соң) 30 көннән дә соңга калмыйча, аларның гаризалары буенча аларга ук тапшырыла. Бу чакта җир асты байлыкларыннан файдалану өчен төзелүче лицензияле килешү шартлары элегрәк төзелгән шартнамә белән чагыштырганда начаррак була алмый.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы әлеге статьяда каралган нигезләрдә юридик затныкы булган очракларда, лицензияне кабат рәсмиләштерүдән баш тартуга яисә тоткарлауга карата судта дәгъва белдерелергә мөмкин.

44 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы оешманың исемен үзгәрткәндә лицензияне кабат рәсмиләштерү

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы оешманың, оештыру-хокукый рәвешен үзгәртмичә генә, исемен үзгәрткәндә элек бирелгән лицензия кабат рәсмиләштерелергә тиеш.

Лицензияне кабат рәсмиләштерү, оешманың яңа исемен күрсәтеп, җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан яңа лицензия бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Яңа лицензия алу өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучы гариза һәм оешманың исемен үзгәртүне раслаучы документлар тапшыра.

45 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензияле килешү

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турындагы карар кабул ителгәннән соң, җир асты байлыкларының дәүләт фон-

дына идарә итү органы лицензияне рәсмиләштергән чорда, җир асты байлыкларыннан файдаланучы белән җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензияле килешү төзелә, ул лицензиянең аерылмас өлеше була. Бирелгән лицензия дәүләт тарафыннан теркәлгән мизгелдән лицензияле килешү юридик көченә керә.

Лицензияле килешүгә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануның кайбер шартларын төгәлләштерүче башка документлар кушымта итеп бирелергә мөмкин.

Лицензияле килешүдә җир асты байлыкларыннан файдалануның мәҗбүри шартлары булырга тиеш һәм бу шартлар килешүнең мөһим шартлары булалар, аларның исемлеге, җир асты байлыкларыннан файдалану төренә карап, әлеге Закон белән беркетелә.

Лицензияле килешүнең шартлары яклар килешүе йә суд карары нигезендә үзгәртелергә мөмкин.

46 статья. Конкурс шартларын лицензияле килешүгә кертү

Конкурста яисә аукционда җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга тәкъдим ителгән һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турындагы карарны кабул итү өчен нигез булган җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары лицензияле килешүгә кертелергә тиеш.

47 статья. Лицензияле килешүнең мөһим шартлары

Лицензияле килешүнең мөһим шартлары, җир асты байлыкларыннан файдалану төренә карамастан, түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

җир асты байлыкларыннан файдалану чорын озайту йә җир асты байлыкларыннан файдалануны вакытыннан алда туктату шартларыннан;

җир асты байлыкларының файдаланылмаучы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бирелгән кишәрлекләрен лицензиянең гамәлдә булу чоры узгач йә вакытыннан алда кире кайтару шартларыннан;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен түләүләрнең һәм җир асты байлыкларыннан файдаланганда законнар нигезендә алынучы башка төрле түләүләрнең шартларыннан;

геологик мәгълүматка хокуктан, аны барлыкка китерү һәм тапшыру шартларыннан, шулай ук аны файдаланудан йә аның белән алыш-биреш итүдән;

төзелгән лицензияле килешүдәге йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучының һәм дәүләт идарәсе органнарының җаваплылыгыннан.

Лицензиядә әлеге статьяның беренче өлешендә каралган

шартларның берәрсе булмаса, лицензияле килешү төзелмәгән дип санала.

48 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә лицензияле килешүнең мөһим шартлары

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү турындагы лицензияле килешүдә, әлеге Законның 47 статьясындагы беренче өлешендә каралган шартлар белән бергә, түбәндәгеләр дә булырга тиеш:

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү шартлары;

геологик бүлеп бирелгән өлешнең чикләрен үзгәртү шартлары;

геологик бүлеп бирелгән өлешнең чикләрен үзгәрткәндә билгеләнгән түләүләрне яңадан исәпләү шартлары;

тапшырылучы геологик мәгълүмат күләме;

җир асты байлыкларын саклауга юнәлдерелгән чаралар.

49 статья. Файдалы казылмалар чыгарганда лицензияле килешүнең мөһим шартлары

Файдалы казылмалар чыгару шартлары турындагы лицензияле килешүдә, әлеге Законның 47 статьясындагы беренче өлешендә каралган шартлардан гайре, түбәндәгеләр дә булырга тиеш:

чыгарырга рөхсәт ителгән файдалы казылманың төре;

файдалы казылмаларны чыгаруның техник проектын әзерләүнең һәм аңа дәүләт экспертизасының вакыты һәм шартлары;

файдалы казылмаларны чыгаруның килешенгән дәрәҗәсе һәм аларны югалтуларның рөхсәт ителгән нормативлары;

җир асты байлыкларын нәтиҗәле эшкәртү һәм аларны саклау шартлары;

минераль чималны җир асты байлыкларыннан файдаланучы белән дәүләт арасында бүлү шартлары яисә чыгарылган файдалы казылмаларның бер өлешен дәүләткә сату шартлары;

минераль чималга милекчелек хокукы һәм милекчелек хокукы күчү шартлары;

файдалы казылмаларның яңа табылган запасларын эшкәртү лицензиясе хуҗасының җир асты байлыклары кишәрлеген сәнәгати эксплуатацияләве барышындагы хокукы;

җир асты байлыкларыннан файдалануны туктатканда тау эшләре предприятиесен консервацияләү йә бетерү шартлары;

инженерлык коммуникацияләреннән файдалану мөмкинлеге һәм аларны эксплуатацияләү шартлары;

файдалы казылмаларны чыгарганда аларны җир асты байлыкларыннан комплексла аерып алу шартлары;

146

тау эшләре житештерүе калдыкларын куллану (файдалы эшкә тоту) һәм күмү шартлары, агып төшүче суларны агызып чыгару шартлары.

50 статья. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланганда лицензияле килешүнең мөһим шартлары

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланганда лицензияле килешүдә, әлеге Законның 47 статьясындагы беренче әлешендә каралган шартлардан гайре, түбәндәгеләр дә булырга тиеш:

җир асты корылмаларын куллануның характеры һәм билгеләнеше;

җир асты корылмаларын төзүнең техник проектына карата таләпләр һәм техник проектны экспертизалау шартлары;

җир асты корылмаларын төзүнең һәм аларны эксплуатацияләүгә тапшыруның вакытлары;

су алуларның санитар саклау зоналарын оештыру шартлары;

тау эшләре өчен бүлеп бирелгән өлеш чикләрендә җир асты сулары мониторингы шартлары;

агып төшүче суларны агызып чыгару һәм сәнәга калдыкларын күмү күләме, агулы концентрацияләрнең һәм башка төрле зарарлы матдәләрнең күләме;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын консервацияләү һәм бетерү шартлары.

51 статья. Махсус сакланылучы геологик объектларны барлыкка китерү һәм минералогик коллекцияләрне җыю өчен җир асты байлыкларыннан файдаланганда лицензияле килешүнең мөһим шартлары

Махсус сакланылучы геологик объектларны барлыкка китерү өчен җир асты байлыкларыннан файдаланганда лицензияле килешүнең мөһим шартлары, әлеге Законның 47 статьясында каралганнардан гайре, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

52 статья. Лицензия һәм лицензияле килешү шартларына ризалык бирүче дәүләт органнары исемлеге

Лицензия һәм лицензияле килешү шартларына ризалык бирүче дәүләт органнары исемлеге һәм килештерү тәртибе җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тәкъдиме буенча Татарс-

147

тан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## V бүлек. Җир асты байлыкларыннан концессия шартнамәләре яисә башка төрле килешүләр шартларында файдалану

### 53 статья. Җир асты байлыкларыннан концессия шартнамәләре яисә продукцияне бүлешү турындагы килешү шартларында файдалану

Инвесторга җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан төзелүче концессия шартнамәләре яисә продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында бирелергә мөмкин.

Концессия шартнамәләре файдалы казылмалар чыгару өчен һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану өчен төзеләләр.

Җир асты байлыкларын чыгаруга концессия шартнамәләре үткәрелгән конкурслар йә аукционнар нәтиҗәләре буенча төзелергә мөмкин.

Концессия шартнамәсе шартларында инвестор сыйфатында бары тик чит илләрнең юридик затлары гына була алалар.

### 54 статья. Продукцияне бүлешү турындагы килешү

Продукцияне бүлешү турындагы килешү - чыгарылган файдалы казылмаларның гомуми күләменнән инвестор чыгымнарын түләттерү өчен килешүдә билгеләнгән өлешен алганнан соң чыгарылган файдалы казылмаларны (минераль чималны) өлешләп бүлү шартларында файдалы казылмалар чыгару йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан инвестор белән төзелә торган шартнамә ул.

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр һәм инвестор керемнәренә салым салу продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакындагы гамәлдә булган законнар нигезендә чыгарылган файдалы казылмаларны (минераль чималны) бүлешү шартлары белән билгеләнә.

Продукция бүлешү шартларында Татарстан Республикасы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы арасында шартнамәләр төзегәндә минераль чималны бүлешү күз алдында тотыла. Мондый шартнамәләрнең шартлары буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы салымнарны һәм салым турындагы законнарда каралган башка түләүләрне Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче өлешендә тү-

148

ләүдән азат ителергә мөмкин, моңа шартнамә шартларында җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бүләкләү рәвешендә бирелүче продукция өлешеннән табышка салым һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр керми, ә продукциянең үзенә тигән өлешен сатудан Татарстан Республикасына килгән керем төрле дәрәҗәләрдәге бюджетлар белән бюджеттан тыш тиешле дәүләт фондлары арасында бүленә.

55 статья. Концессия шартнамәләре һәм продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану вакыты

Концессия шартнамәләре яисә продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану вакыты җир асты байлыкларыннан файдалануның әлеге Законда билгеләнгән вакытларын үтәгән килеш, концессия шартнамәсендә йә продукцияне бүлешү турындагы килешүдә билгеләнә.

Концессия шартнамәләре һәм продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану вакытын озайту күрсәтелгән шартнамәләрдә һәм килешүләрдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

56 статья. Концессия шартнамәләре яисә продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясен инвесторга бирү тәртибе

Концессия шартнамәләре шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясе юридик көченә кергән концессия шартнамәсе нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланунын дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан бирелергә һәм теркәлергә тиеш.

Продукцияне бүлешү турында килешү төзегәндә лицензия һәм аны теркәү "Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

57 статья. Концессия шартнамәләренең яисә продукция бүлешү турындагы килешүләрнең мөһим шартлары

Концессия шартнамәләрендә яисә продукцияне бүлешү турындагы килешүләрдә түбәндәге мөһим шартлар булырга тиеш:

инвестицияләрне файдалану шартлары һәм күләме;

бирелгән җир асты кишәрлеген үзләштерә башлау вакытлары;

тау эшләре предприятиеләрен төзү шартлары;

жир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр туктатылганда җир кишәрлеген кире кайтару йөкләмәләре;

җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча инвесторның конкрет гамәлләре;

бәхәсләрне хәл итү тәртибе, ә концессия шартнамәләре өчен - кулланылырга тиешле хокук та.

Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләреннән гайре, төзелгән концессия шартнамәләре һәм продукцияне бүлешү турындагы килешүләр чикләрендәге башка мөнәсәбәтләр законнар белән җайга салына.

<u>58 статья.</u> Концессия шартнамәләрен төзегәндә тау эшләре кишәрлекләрен һәм җир кишәрлекләрен бирү тәртибе

Концессия шартнамәләрен төзегәндә тау эшләре кишәрлекләрен бүлеп бирү тәртибе әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Концессия шартнамәләрен төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану өчен җир кишәрлекләрен инвесторга бирү нигезләре һәм шартлары җир турындагы законнар нигезендә шушы шартнамәләрдә билгеләнәләр.

<u>59 статья.</u> Концессия шартнамәсе шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату әлеге Законда каралган нигезләрдә һәм тәртиптә инвесторлар белән төзелгән концессия шартнамәсе шартларында гамәлгә ашырыла.

Инвесторның җир асты байлыкларыннан файдаланучы буларак эшчәнлеген туктату, әлеге Законның тау эшләре предприятиеләрен бетерүгә һәм (яисә) консервацияләүгә карата таләпләрен исәпкә алып, тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органнарына һәм салым инспекциясе органнарына хәбәр иткән килеш гамәлгә ашырыла.

Концессия шартнамәсенең гамәлдә булуын туктатканда җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы да туктатыла.

## VI бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләү

<u>60 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдалануның түләүле булуы

Әлеге Законда каралган очраклардан гайре, җир асты байлыкларыннан файдалану түләүле була. Билгеләнгән тәртиптә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алган затлар җир асты

байлыкларыннан файдаланган өчен түләүчеләр булалар.

Файдалы казылмалардан файдаланган өчен түләү ставкалары һәм шушы түләүләрне төрле дәрәҗәдәге бюджетлар белән бюджеттан тыш тиешле фондлар арасында бүлү тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең ставкаларын исәпләп чыгару тәртибе, аларны түләтү шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан әлеге Закон нигезендә раслана.

61 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү төрләре

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түбәндәге даими түләү төрләре башкарыла:

җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү;

файдалы казылмалар чыгарган өчен түләү;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү;

минераль чимал базасын торгызуга һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруга бирелүче түләүләр.

Моннан тыш түбәндәге түләүләр алына:

конкурста яисә аукционда катнашкан өчен һәм лицензия алган өчен җыемнар;

геологик мәгълүмат өчен түләү;

лицензия өчен һәм (яисә) коммерциячел ачыш өчен бер мәртәбә башкарыла торган түләү;

62 статья. Түләү рәвешләре

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү түбәндәге рәвешләрдә кертелергә мөмкин:

акчалата түләүләр;

минераль чимал өлеше;

түләү суммасы күләмендә эшләрнең конкрет төрен башкару.

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр лицензия гамәлдә булган барлык чорда бер мәртәбә түләнә торган взнослар (бонуслар) һәм шуннан соң даими түләнә торган түләүләр (роялтилар) рәвешендә алына. Түләүне кертү рәвеше лицензияле килешүдә билгеләнә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү сыйфатында бары тик Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагында гына булган радиоактив материалларны һәм продуктларны таләп

иту һәм кабул иту рөхсәт ителми.

63 статья. Лицензияләр биргән өчен җыем

Лицензия биргән өчен җыем күләме һәм аны алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

64 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкарган өчен түләү күләме, икътисадый-географик шартларны, җир асты байлыклары кишәрлегенең күләмен, файдалы казылманың төрен, эшләрнең дәвамлылыгын, территориянең геологик өйрәнелү дәрәҗәсен һәм хәвеф-хәтәрлек дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнә.

Түләүләр җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкаруның барлык чорында билгеләнгән тәртиптә даими кертеләләр һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучының чыгымнарына өстәләләр.

65 статья. Файдалы казылмалар чыгарган өчен түләү

Файдалы казылмалар чыгарган өчен түләү күләме, файдалы казылманың төрен, аның запасларының микъдарын һәм сыйфатын, табигый-географик шартларны, тау эшләренең техник шартларын, ятмаларны эшкәртүнең рентабельлеген һәм хәвеф-хәтәрлек дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнә.

Файдалы казылмалар чыгарган өчен түләү ставкасы реализацияләнгән минераль чимал хакының бер өлеше буларак билгеләнә.

66 статья. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен, шул исәптән җир асты корылмаларын төзегән һәм аларны эксплуатацияләгән өчен түләү күләме куллануга бирелүче җир асты байлыклары кишәрлегенең күләмнәрен, җир асты байлыкларының файдалы үзлекләрен һәм аңардан файдаланганда экологик хәвеф-хәтәрлек дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнә.

Бу чакта түләү күләме файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану буенча башкарылган эшләр яисә күрсәтелгән хезмәтләр хакының бер өлеше буларак билгеләнә.

152

67 статья. Минераль чимал базасын торгызуга һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруга кертемнәр

Минераль чимал базасын торгызуга һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруга кертемнәр, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен башка түләүләрдән тыш, җир асты байлыкларыннан файдалы казылмалар чыгару өчен файдаланучылардан алына.

Кертемнәрнең ставкасы реализацияләнгән файдалы казылмалар (минераль чимал) хакының зурлыгына карата процент чагыштырмасында билгеләнә һәм файдалы казылманың (минераль чималның) конкрет төрен чыгаручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның барысы өчен дә бердәй була.

Минераль чимал базасын торгызуга кертемнәр продукциянең үзкыйммәтенә кертелә.

Минераль чимал базасын торгызуга һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруга финанс чараларын бюджеттан тыш фондлар турындагы Татарстан Республикасы законнары нигезендә бергә туплау өчен минераль ресурсларның запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча бюджеттан тыш фонд башкара. Күрсәтелгән фондны гамәлгә кую, аның эшчәнлеге һәм аны бетерү тәртибе бюджеттан тыш фондлар турындагы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

Углеводород чыгаручы предприятиеләрнең чимал базасына ярдәм күрсәтү максатларында әлеге статьяның икенче өлешендә каралган кертемнәрнең бер өлеше шул предприятиеләрнең үтенечләре буенча геологик-разведкалау эшләренә җибәрелергә һәм ул ресурслар һәм файдалы казылмалар запасларын торгызу һәм аларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча республика программасы нигезендә кулланылырга мөмкин.

Нефть бирүчәнлекне арттыру ысуллары исәбенә, авыр чыгарылучы, кондициясез, баланстан тыш, элек исәптән төшереп калдырылган файдалы казылмалар запаслары исәбенә нефть чыгарганда, ТЭОда яисә әлеге ятмаларны эшкәртү буенча проект документларында билгеләнгән башлангыч стадиядәге яңа ятмаларны үзләштергәндә капитал кертемнәрнең хакын кире кайтару вакытына, шулай ук җир куенының ачык һәм күчүчән токымнарын, файдалы казылмалар чыгаручы һәм шуңа бәйле эшкәртү производстволарыннан файдаланганда әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән кертемнәр ясалмый.

Минераль чимал базасын торгызуга кертемнәрнең бер ярым процентка кадәр өлеше файдалы казылмалар ятмаларын ачкан һәм

153

разведкалаган өчен түләүгә җибәрелә.

Минераль ресурслар запасларын торгызуның һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруның бюджеттан тыш фонды акчаларын җыю һәм куллану тәртибе җир асты байлыкларыннан файдалануның дәүләт фонды идарәсе органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

68 статья. Лицензия һәм (яисә) коммерциячел ачыш өчен бер мәртәбә түләү

Лицензия һәм (яисә) коммерциячел ачыш әчен бер мәртәбә түләү күләме һәм аны алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

69 статья. Җир асты байлыклары турында дәүләт акчалары исәбенә алынган геологик мәгълүмат өчен түләү

Дәүләт акчалары исәбенә геологик мәгълүмат алган һәм аннан файдаланган өчен, шулай ук файдалы казылмалар яткан урыннары булган районнар буйлап җир асты байлыклары турындагы шундый геологик мәгълүматларны тормышка ашыруга карата теләсә нинди алыш-биреш гамәлләренә рөхсәт алган өчен түләүләр тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

70 статья. Чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүгә скидкалар

Түбәндәгеләрне чыгаруга бәйле рәвештә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүгә скидкалар ясалырга мөмкин:

дефицит файдалы казылмаларны;

ятмаларны эшкәртүнең объектив рәвештә билгеләнгән түбән икътисадый нәтиҗәлелеге аркасында (запаслар азаю очрагында, шулай ук нефть ятмалары катламнарында 85 процентыннан артыграгы сулы булган очракларда һәм нефтьнең артык үзле ятмалары, түбән коллектор үзлекле катламнары булган очракларда) файдалы казылмаларны.

Чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүләрнең ставкаларына скидкалар зурлыгын билгеләү тәртибе законнар белән урнаштырыла.

71 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган әчен түләүләрдән азат итү

Түбәндәгеләр җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрдән азат ителәләр:

геологик-геофизик эшләрне, геологик рәсемгә төшерүне, җир асты байлыкларын гомуми геологик өйрәнүгә юнәлдерелгән башка геологик эшләрне, җир тетрәүләрне фаразлау буенча геологик эшләрне, геоэкологик тикшеренүләрне, җир асты сулары режимын тикшереп торуны, файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәртү өчен разведкалауны һәм әзерләүне, шулай ук җир асты байлыкларының бөтенлеген сизелерлек бозмыйча дәүләт акчалары исәбеннән башкарылучы бүтән эшләрне алып баручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар;

үзләре карамагындагы җир кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмаларны һәм җир асты суларын турыдан-туры үз ихтыяҗлары өчен чыгаруны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыручы җир кишәрлекләре милекчеләре, биләүчеләре;

махсус сакланылучы геологик объектлар барлыкка китерү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен алган җир асты байлыкларыннан файдаланучылар.

Чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүдән җир асты байлыкларыннан түбәндәге файдаланучылар азат ителә:

файдалы казылмалар чыгаруны яңа, экологик яктан хәвефсез һәм алдынгы ысуллар нигезендә эшләүне шушы ысулларны эшләүнең тәҗрибә-конструкторлык һәм тәҗрибә-сәнәга стадияләрендә алып баручылар;

файдалы казылмалар чыгарган вакытта, әгәр аларны чыгару лицензиядә килешенмәгән булса, ияреп чыгучы компонентларны реализацияләгәндә;

яңа технологияләрне гамәлгә керткәндә файдалы казылмалар югалтуларны киметү исәбенә алынучы продукциядән;

дәүләт бюджеты исәбеннән йә һөнәр берлекләре исәбеннән финансланучы һәм файдалы казылмалардан дәвалау максатларында файдаланучы дәвалау учреждениеләре;

билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәт булганда, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында төче сулар җыюны башкаручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар.

72 статья. Түләүләрне кичектерү һәм аларның вакытын озайту тәртибе

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне кичектерү һәм аларны түләүнең вакытын озайту законнар нигезендә

башкарыла.

## VII бүлек. Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау

### 73 статья. Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау буенча төп таләпләр

Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануның һәм аларны саклауның төп таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

җир асты байлыкларын файдалануга бирүнең законнарда билгеләнгән тәртибен үтәү һәм җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалануга юл куймау;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең, алардан нәтиҗәле комплекслы файдалануның һәм аларны саклауның бөтенлеген тәэмин итү;

файдалы казылмаларның запасларын яисә файдалы казымаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалануга тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлегенең үзлекләрен дөрес бәяләүне тәэмин итәрлек итеп җир асты байлыкларын алдан геологик өйрәнү;

файдалы казылмалар запасларына, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда кулланылучы җир асты байлыклары кишәрлекләренә дәүләт экспертизасы уздыру һәм аларны дәүләт исәбенә алу;

җир астыннан төп һәм аның янәшәсендәге файдалы казылмаларның һәм аларга ияреп чыгучы компонентларның запасларын тулырак аерып алуны тәэмин итү;

файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәрткәндә җир астыннан чыгарыла һәм анда калдырыла торган төп һәм аның янәшәсендәге файдалы казылмаларның, аларга ияреп чыгучы компонентларның запасларын дөрес итеп исәпкә алу;

файдалы казылмаларның ятмаларын су басудан, суландырудан, янгыннардан һәм файдалы казылмаларның сыйфатын, ятмаларның сәнәга кыйммәтен киметерлек яисә аларны эшкәртүне катлауландырырлык бүтән факторлардан саклау;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкарганда, бигрәк тә нефть, газ яисә бүтән матдәләрне һәм материалларны җир астында саклаганда, радиоактив, зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмгәндә, агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләре булганнарын да) агызып чыгарганда җир асты байлыкларын пычратуны кисәтү;

файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләрне һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын консервацияләүнең һәм бетерүнең билгеләнгән тәртибен үтәү;

файдалы казылмалар яткан мәйданнарда рөхсәтсез төзелеш алып баруны кисәтү һәм бу мәйданнардан бүтән максатларда файдалануның билгеләнгән тәртибен үтәү;

эчәр сулар һәм сәнәгане сулар белән тәэмин итү өчен кулланылучы су җыю мәйданнарында һәм җир асты сулары яткан урыннарда сәнәга һәм көнкүреш калдыклары туплауны булдырмау.

74 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү түбәндәгеләрне күз алдында тота:

җир асты байлыкларының геологик төзелеше һәм алардагы файдалы казылмаларга тасвирлама һәм аларны сәнәга эшкәртүе мөмкинлекләре турында мәгълүмат җыюны, саклауны һәм эшкәртүне;

файдалы казылмалар ятмаларын табу өчен җир асты байлыкларының перспективалы кишәрлекләрен ачуны;

табылган ятмалардагы файдалы казылмаларны эшкәртүнең һәм минераль чималны комплекслы куллануның нәтиҗәле ысулын билгеләү өчен аларның тибын, күләмен, сыйфатын һәм технологик үзлекләрен билгеләүне;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләрен ачыклауны;

геологик процессларның һәм күренешләрнең (җир кабыгы хәрәкәтләренең, җир тетрәүләрнең, карст күренешләренең, шуышуларның һәм башкаларның) хуҗалык эшчәнлегенә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга йогынтысын исәпкә алу өчен алар турында белешмәләр алуны;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда куллану максаты белән геоэкосистеманың торышы турында мәгълүмат җыюны һәм исәпкә алуны (геологик картага төшерүне);

геологик-геофизик һәм инженерлык-геологик эшләр башкаруны;

җир асты сулары режимын өйрәнүне;

фәнни-тикшеренү, палеонтологик һәм җир асты байлыкларын гомуми өйрәнүгә юнәлтелгән бүтән эшләр башкаруны;

геологик коллекция материалларын җыюны.

75 статья. Геологик эшләрне дәүләт исәбенә һәм дәүләт теркәвенә алу

Милек рәвешләренә карамастан, барлык оешмалар тарафыннан башкарылучы, шул исәптән файдалы казылмалар чыгару һәм аларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрендә җир асты байлыкларын геологик өй-

157

рәнүнең барлык эшләре, шулай ук разведкаланган ятмаларның сәнәга запаслары һәм запасларның тиешле категорияләре буенча үзгәрешләр дәүләт исәбенә һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен дәүләт исәбенә һәм дәүләт теркәвенә алу тәртибе җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан билгеләнә.

76 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне финанслау

Дәүләт программалары кысаларында геологик өйрәнү минераль ресурслар запасларын торгызуның һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча бюджеттан тыш фонд акчалары исәбенә һәм законнарда каралган башка чыганаклар исәбенә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Каты файдалы казылмалар ятмаларын, эзләүне һәм бәяләүне дә кертеп, геологик өйрәнүне финанслау минераль ресурслар запасларын торгызуның һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча бюджеттан тыш фонд яисә дәүләт фонды акчалары исәбенә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Аеруча дефицит яисә стратегик чималны разведкалаудан гайре, ятмаларны разведкалау җир асты байлыкларыннан файдаланучы исәбенә башкарыла, аларның исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

77 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә карата төп таләпләр

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

җир асты байлыкларын өйрәнүнең комплекслылыгы һәм дәреслеге, моңа файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең тау эшләре технологиясе, гидрогеологик, икътисадый шартлары, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең башка шартлары да керә;

төп һәм алар янәшәсендәге файдалы казылмалар, алардагы компонентлар запасларының күләмен һәм сыйфатын билгеләүнең дәреслеге;

киләчәктә җир асты байлыкларын өйрәнгәндә, файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәрткәндә, шулай ук файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларын файдаланганда кулланылырга мөмкин булган геологик һәм башкарма-техник документларның, тау токымнары һәм рудалар, керн үрнәкләренең, файдалы казылмалар үрнәкләре дубликатларының сак-

158

ланышы.

78 статья. Җир асты байлыклары турындагы геологик мәгълүматка милекчелек

Җир асты байлыкларының геологик төзелеше, алардагы файдалы казылмалар запаслары һәм аларның ятмалары, аларны эшкәртү шартлары турында, шулай ук җир асты байлыкларының башка сыйфатлары һәм үзенчәлекләре турында мәгълүмат, әгәр лицензияле килешүдә башкасы каралмаган булса, шуларны үткәрү нәтиҗәсендә алынган мәгълүмат шушы эшләрне финанслаган зат милке була.

Финанслау чыганагына карамастан, җир асты байлыклары турындагы теләсә нинди геологик мәгълүмат Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына ул билгеләгән рәвештә кертелә.

Дәүләт акчалары исәбенә алынган геологик мәгълүматны куллану тәртибе һәм шартлары җир асты байлыкларыннан файдалануның дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан билгеләнә.

Үз акчалары исәбенә геологик мәгълүмат алган оешмаларның һәм гражданнарның әлеге мәгълүматны биреп тору тәртибе, шулай ук аны Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фонды тарафыннан куллану шартлары лицензияле килешүдә билгеләнәләр.

79 статья. Файдалы казылмалар ятмалары өчен минераль чималга карата кондицияләр

Ятмаларның сәнәга әһәмиятен билгеләү һәм алардагы запасларны исәпләп чыгару өчен, киләчәктә аларның һәр ятма буенча комплекслы кулланылышын ачыклау өчен минераль чималга карата кондицияләр билгеләнә, бу кондицияләр файдалы казылмаларның сыйфатына һәм күләменә, ятмаларны эшкәртүнең тау эшләре геологиясе һәм башка шартларына карата икътисадый нигезләнгән таләпләрнең бергәлегеннән гыйбарәт.

Минераль чималга карата кондицияләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә раслана.

80 статья. Файдалы казылмалар ятмаларының һәм алар табылган урыннарның дәүләт кадастры

Файдалы казылмалар ятмаларының һәм алар табылган урыннарның дәүләт кадастры - дәүләт исәбенә алынырга тиешле файдалы казылмаларның һәр ятмасы һәм һәр табылган урын буенча белешмәләрнең системалаштырылган җыелмасы ул.

159

Файдалы казылмалар ятмаларының һәм алар табылган урыннарның дәүләт кадастрында һәр ятма буенча аның геологик төзелешен, төп һәм аның янәшәсендәге файдалы казылмаларның, алардагы компонентларның күләмен һәм сыйфатын тасвирлаучы белешмәләр, ятмаларны эшкәртүнең тау эшләре - техник, гидрогеологик, экологик һәм башка шартлары, ятмага геологик-икътисадый бәяләмә, шулай ук файдалы казылмаларның һәр табылган урыны буенча ресурсларның геологик төзелеше һәм фаразлау бәяләве турында белешмәләр булырга тиеш.

<u>81 статья.</u> Файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансы

Файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансы - сәнәгать әһәмиятенә ия ятмалар буенча һәр төр файдалы казылмалар запасларының күләме, сыйфаты һәм өйрәнелү дәрәҗәсе хакындагы, аларның урнашуы, сәнәгадә үзләштерелү дәрәҗәсе, чыгарылышы, югалтулары, разведкаланган файдалы казылмалар белән сәнәганең тәэмин ителеше турындагы белешмәләрнең системалаштырылган җыелмасы ул. Файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансын Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фонды алып бара.

Файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансы файдалы казылмалар разведкалаучы һәм чыгаручы оешмаларның дәүләт статистика хисабы нигезендә төзелә.

Запасларның дәүләт балансы файдалы казылмалар ятмалары һәм техноген ресурслар өчен аерым-аерым төзелә.

<u>82 статья.</u> Файдалы казылмалар запасларын исәптән төшереп калдыру

Чыгарылган файдалы казылмалар, шулай ук сәнәга әһәмиятен югалткан, чыгару барышында югалган, кабат геологик разведкалау эшләре алып барганда яисә ятмаларны эшкәрткәндә расланган файдалы казылмалар запаслары, файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансында тиешле үзгәрешләр күрсәтелгән килеш, файдалы казылмалардан файдаланучы предприятиеләр исәбеннән Татарстан Республикасы законнарында билгеләнүче тәртиптә төшереп калдырыла.

<u>83 статья.</u> Файдалы казылмалар ятмаларын беренче ачучылар

Сәнәга кыйммәтенә ия булган ятмаларны ачучы, шулай ук файдалы казылмаларның өстәмә запасларын, шулай ук элек мәгълүм булган ятмада аларның сәнәга әһәмиятен шактый арттырырлык яңа куллану өлкәләрен ачучы яисә ятмалар ачу мөмкинлеген теоретик

нигезләүче физик затлар беренче ачыш ясаучылар дип танылa. Алар үз ачышын җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органында теркәргә хокуклы. Ачыш җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланса, беренче ачыш ясаучылар бүләкләнүгә хокуклы булалар.

Бүләкләнү күләме һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

<u>84 статья.</u> Файдалы казылмаларның запасларына һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланырга яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы

Файдалы казылмалар чыгару өчен файдалануга һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалануга тапшыру дәүләт экспертизасы узганнан соң гына рөхсәт ителә.

Разведкаланган ятмаларның файдалы казылмалар запаслары аларның сәнәга үзләштерелеше мөмкинлеген билгеләү максатларында дәүләт экспертизасы үтәргә тиеш.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе разведкаланган файдалы казылмалар запасларын дәүләт исәбенә алу өчен нигез була.

Файдалы казылмалар запасларына дәүләт экспертизасы җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең теләсә кайсы стадиясендә уздырылырга мөмкин, әмма бу чакта экспертизага тапшырылучы геологик материаллар файдалы казылмалар запасларының күләменә һәм сыйфатына, аларның сәнәга әһәмиятенә, шулай ук тау эшләренең техник, гидрогеологик, экологик һәм файдалы казылмаларны чыгаруның башка шартларын объектив бәяләү мөмкинлеген бирергә тиеш.

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану өчен яраклы җир асты байлыкларын геологик өйрәнү нәтиҗәләре дә дәүләт экспертизасы узарга тиеш.

Файдалы казылмалар запасларына һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдалану өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнүгә дәүләт экспертизасы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын бер үк вакытта файдалы казылмаларны геологик өйрәнү һәм чыгару өчен биргәндә, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар, запасларны киләчәктә катгый раслау шарты белән, лицензияле килешүдә билгеләнүче шартларда файдалы

161

казылмалар запасларын экспертизага кадәр үк чыгара башлый алалар.

<u>85 статья</u>. Аерым фәнни һәм мәдәни кыйммәткә ия булган җир асты байлыкларын саклау

Аерым фәнни яисә мәдәни кыйммәткә ия булган сирәк очрый торган геологик ачыклыклар, минералогик төзелмәләр, палеонтологик объектлар һәм җир асты байлыкларының башка кишәрлекләре билгеләнгән тәртиптә геологик тыюлыклар, заказниклар йә табигать яисә мәдәният ядкярләре итеп игълан ителергә мөмкин. Мондый тыюлыкларның, заказникларның һәм ядкярләрнең сакланышын бозарлык теләсә нинди эшчәнлек тыела.

Җир асты байлыкларыннан файдаланганда фән һәм мәдәният өчен кызыклы, сирәк очрый торган геологик һәм минералогик төзелмәләр, метеоритлар, палеонтологик, археологик һәм башка объектлар табылган очракта, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тиешле кишәрлектәге эшләрне туктатып торырга һәм бу хакта лицензия биргән органга хәбәр итәргә тиеш.

VIII бүлек. Җир асты байлыкларын эксплуатацияләү

<u>86 статья.</u> Җир асты байлыкларын эксплуатацияләүнең гомуми тәртибе

Файдалы казылмалар ятмаларын сәнәга үзләштерүе аларны геологик өйрәнүне тәмамлагач һәм уздырылган дәүләт экспертизасы нигезендә разведкаланган файдалы казылмалар запасларын раслагач гамәлгә ашырыла.

Файдалы казылмалар ятмаларын сәнәга эксплуатацияләве җир асты байлыкларыннан, тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлектән файдалану хокукына лицензиясе булган, җир асты байлыкларын сәнәга эксплуатацияләве буенча билгеләнгән тәртиптә расланган техник проектлары, төзелгән лицензияле килешүләр шартларында махсуслаштырылган эш төрләрен башкаруга лицензияләре булган һәм файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Билгеләнгән тәртиптә расланган техник проектлардан башка файдалы казылмалар чыгару һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану тыела.

Файдалы казылмаларның кайбер ятмаларын сәнәгадә үзләштергәндә, ятманы эшкәртүнең техник проекты җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан, ятманы тулаем эшкәртү өчен кирәкле

инженерлык инфраструктурасы һәм коммуникацияләр үсешен исәпкә алып, конкрет ятмаларны эшкәрткәндә кулланылырга тиешле күләмдә үтәлә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы аерым төр эшләрне башкару өчен, эшкәртүнең расланган техник проекты шартлары, бирелгән лицензия һәм төзелгән лицензияле килешү нигезендә бу эшләрне башкару җаваплылыгы сакланып калган килеш, махсуслаштырылган оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

87 статья. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларын эксплуатацияләүнең техник проектларына дәүләт экспертизасы

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларын эксплуатацияләүнең техник проектлары, шул исәптән зарарлы, агулы җитештерү калдыкларын күмү һәм агып төшүче суларны (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләр булганнарын да) агызып чыгару әйләнә-тирә мохитнең торышын һәм сәнәгадә эшләрнең хәвефсез алып барылуын тикшереп торучы дәүләт органнарында дәүләт экспертизасы узарга тиеш.

Эксперт бәяләмәсендә күмелгән продуктлардан йә таркалу продуктларыннан һәм сәнәга калдыкларыннан барлыкка килүче зарарлы һәм агулы матдәләрнең күмелгән урыннарыннан читкә таралу куркынычы юклыгын таныклаучы инженерлык-геологик һәм гидрогеологик белешмәләрнең җитәрлек булуы хакында нәтиҗәләр күрсәтелергә тиеш.

88 статья. Сәнәга эшкәртүе объектлары

Файдалы казылмалар чыгарганда шул ятма яисә аның бер өлеше сәнәга эшкәртүе объекты була.

Файдалы казылмалар ятмасы составындагы яткыннарны эшкәртүнең эзлеклелеге һәм аерым яткыннарны эшкәртүнең технологик үзенчәлекләре, шулай ук аерым яткыннар буенча файдалы казылмалар аерып алуны һәм чыгаруны исәпкә алу эшкәртү проекты белән билгеләнә.

89 статья. Җир асты байлыкларын һәм файдалы казылмаларның ятмаларын сәнәга эксплуатацияләвенә карата төп таләпләр

Файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәртү һәм минераль чималны кабат эшкәртү, шулай ук файдалы казылмаларны чыгаруга

163

бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану түбәндәге төп таләпләрне үтәгән килеш башкарылырга тиеш:

төп һәм аның янәшәсендәге файдалы казылмаларны чыгаруның аеруча нәтиҗәле, экологик имин, ятмаларны бозмый һәм нормадан тыш югалтуларга китерми торган ысулларын куллану, файдалы казылмалар запасларын сайлап эшкәртү;

файдалы казылмаларның эшкәртелүче ятмаларының һәм алар күршесендәге ятмаларның тау эшләрен башкару нәтиҗәсендә бозылуын булдырмау, шулай ук җир куенында консервацияләнгән файдалы казылмалар запасларын һәм киләчәктә кулланылырга тиешле җир асты байлыкларының эшкәртелгән киңлекләрен саклап калу;

каты, сыек файдалы казылмаларны саклап калу, чыгарылган һәм вакытлыча кулланылмый торган ияреп чыгучы файдалы казылмаларны исәпкә алу;

файдалы казылмалар чыгаруның икътисадый рентабельле технологияләре булганда һәм җитештерү планнары нигезендә минераль чималны, ияреп чыгучы кыйммәтле компонентларны аерып алып, комплекслы кабат эшкәртү;

ачык катламнарны нәтиҗәле файдалану, шулай ук аларны дөрес урнаштыру;

минераль чималны беренчел эшкәрткәндә әлеге чималдагы компонентларны мөмкин булганча максималь һәм комплекслы аерып алуны тәэмин итүче геологик-сәнәга типларына карата кабат эшкәртүнең кабул ителгән технологик схемаларын мәҗбүри үтәү һәм экологик нормативларны үтәү;

запасларның торышы һәм хәрәкәте, минераль чималны югалтулар һәм ярлыландыру мәсьәләләре буенча исәп алып бару һәм дәүләт статистика хисабын ясау, шулай ук җир асты байлыкларының ятмасын, эшкәртелгән киңлекләрен үзләштерүнең һәм файдалануның комплекслылыгын һәм тау массивында шуңа бәйле рәвештә килеп чыгучы киеренкелекне исәпкә алу;

файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләр хезмәткәрләренең һәм халыкның гомере, сәламәтлеге өчен иминлек, экологик иминлек, җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә табигать мохитенең башка объектларын, биналарны һәм корылмаларны саклауны тәэмин итү;

агып төшүче суларны, зарарлы матдәләрне, җитештерү калдыкларын һәм башка матдәләрне, материалларны зарарсызландыру йә аларны катгый билгеләнгән чикләрдә тотып калу һәм аларның тау эшләнмәләренә җир өслегенә һәм су объектларына үтеп керүен булдырмау, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны тәэмин итүче башка гамәлләр;

тау эшләрен һәм шартлату эшләрен алып бару стандартларын һәм кагыйдәләрен үтәү.

164

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән таләпләрне үтәүне тикшереп торуны үзләренә йөкләнгән вәкаләтләр нигезендә тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органнары һәм геологик контроль органнары башкара.

90 статья. Техноген төзелмәләрнең хокукый режимы

Җир асты байлыкларын сәнәга эксплуатацияләве нәтиҗәсендәге техноген төзелмәләр (шул исәптән минераль чимал төзелмәсе, файдалы казылмаларны чыгару барышында аларны эшкәртүдән калган калдыклар һәм продуктлар, шлам һәм калдыкларны саклагычлар, токымнар һәм рудалар өеме) паспортлаштырылырга тиеш.

Файдалы казылмалар чыгару яисә җир асты байлыкларын башкача сәнәга эксплуатацияләве нәтиҗәсендәге техноген төзелмәләрне эшкәртү объектларын проектлаштыруга төзүгә һәм эксплуатацияләүгә карата әлеге Законның VIII бүлегендәге җир асты байлыкларын сәнәга эксплуатацияләве шартларына һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын раслау тәртибенә карата куелган таләпләр кулланыла.

91 статья. Файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләрне һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын бетерү, консервацияләү

Лицензиянең гамәлдә булу вакыты узгач яисә җир асты байлыкларыннан файдалану вакытыннан алда туктатылганда, файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләр һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары әлеге Законда каралган нигезләрдә бетерелергә яисә консервацияләнергә тиеш.

Бетерү яисә консервацияләү процессы тәмамланганчы җир асты байлыкларыннан файдаланучы әлеге Закон үзенә йөкләгәнчә җаваплы була.

Предприятие йә җир асты корылмасы тулысынча яисә өлешчә бетерелгәндә яки консервацияләнгәндә тау эшләнмәләре һәм бораулау скважиналары халыкның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, әйләнә-тирә табигать мохитен, биналарны һәм корылмаларны саклауны тәэмин итәрлек халәткә китерелергә тиеш, ә консервацияләнгәндә - консервацияләү вакытына шулай ук ятманың, тау эшләнмәләренең һәм бораулау скважиналарының сакланышы да тулысынча тәэмин ителергә тиеш.

Файдалы казылмаларны чыгаручы предприятие яисә аның бер өлеше, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмасы бетерелгәндә яисә консервацияләнгәндә геологик,

165

маркшейдерлык документлары һәм бүтән төр документлар эшләр тәмамлану моментына тутырыла һәм билгеләнгән тәртиптә саклауга тапшырыла.

Лицензия биргән органнар һәм тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органы тарафыннан файдалы казылмалар чыгаручы предприятиене яисә файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмасын бетерү яисә консервацияләү турындагы актка имза салынганнан соң аларны бетерү һәм консервацияләү төгәлләнгән дип санала.

Тау эшләнмәләрен һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны консервацияләү яисә бетерү җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятиеләр акчалары исәбенә башкарыла.

Әгәр җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы әлеге Законның 31 статьясындагы беренче өлешендә һәм икенче өлешенең 2-5 абзацларында каралган нигезләрдә туктатылса, тау эшләре предприятиесен консервацияләү һәм (яисә) бетерү чыгымнары җир асты байлыкларыннан файдаланучыга йөкләнә. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы әлеге Законның 31 статьясындагы икенче өлешнең 6 абзацында каралган нигезләрдә туктатылган очракта, күрсәтелгән чыгымнар, әгәр лицензияле килешүдә башкасы билгеләнмәгән булса, дәүләткә йөкләнә.

Чыгымнарны түләтү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителә.

### 92 статья. Файдалы казылмалар яткан мәйданнарны төзү шартлары

Торак пунктларын, сәнәга комплексларын һәм башка хуҗалык объектларын проектлаштыру һәм төзү бары тик төзелеш булачак кишәрлекнең җир куенында файдалы казылмалар юклыгы турында җир асты байлыкларыннан файдалануның дәүләт фонды идарәсе органыннан бәяләмә алгач кына рөхсәт ителә.

Файдалы казылмалар яткан мәйданнарны төзү, шулай ук алар яткан урыннарда җир асты корылмалары урнаштыру лицензия хуҗасы яисә җир асты байлыкларыннан файдалануның дәүләт фонды идарәсе органы рөхсәте белән башкарыла. Бу чакта файдалы казылмаларны чыгару мөмкинлеге тәэмин ителергә яисә төзелешнең икътисадый максатка ярашлылыгы дәлилләнгән булырга тиеш.

166

## 1Х бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен дәүләт тарафыннан җайга салу

### 93 статья. Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләти геологик тикшереп тору

Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләти геологик тикшереп тору бурычы җир асты байлыкларыннан барлык файдаланучыларның җир асты байлыкларын файдалануга тапшыруның законнарда билгеләнгән тәртибен, җир асты байлыкларын эксплуатацияләүнең, җир асты байлыкларын саклауның стандартларын (нормаларын, кагыйдәләрен), шулай ук файдалы казылмалар запасларын һәм ятмаларын дәүләт исәбенә алу кагыйдәләрен үтәүләрен тәэмин итүдән гыйбәрәт.

Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләти геологик тикшереп тору Татарстан Республикасының җир асты байлыклары дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан дәүләт күзәтчелегенең һәм тикшереп торуының башка органнары белән берлектә гамәлгә ашырыла.

### 94 статья. Дәүләти геологик тикшереп торуны гамәлгә ашыручы органның хокуклары һәм вазыйфалары

Дәүләти геологик тикшереп торуны гамәлгә ашыручы орган түбәндәгеләргә хокуклы:

җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, куллану, файдалану һәм саклау эшләрен алып баруда урындагы затларга бу эшләрне башкару тәртибен бозуларын төзәтүләре турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне бозып башкарылса һәм алар ятмаларны бозуга китерә торган булса, бу эшләрнең барлык төрләрен туктатып торырга;

тикшерү нәтиҗәләре, җир асты байлыкларыннан файдалану шартларының бозылуы турында, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр кертү, стандартларның (нормаларның, кагыйдәләрнең) үтәлеше өлешендә дә, җир асты байлыкларыннан файдаланучыга һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өчен аңа лицензия биргән органнарга язма рәвештә хәбәр итәргә, ә кирәк чакта җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясен туктатып тору яисә юкка чыгару турында тәкъдимнәр ясарга;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, куллану һәм саклау

167

эшләрен алып баруның стандартларын (нормаларын, кагыйдәләрен) үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан язмача аңлатма соратып алырга;

җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр кертү вакытлары һәм түләүләрнең күләмнәре үтәлмәү турындагы материалларны салым органнарына җибәрергә;

тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органнары белән берлектә, җир асты байлыкларыннан башбаштакланып файдалануны һәм файдалы казылмалар яткан мәйданнардагы рөхсәтсез төзелешне билгеләнгән тәртиптә туктатырга, шулай ук радиоактив матдәләрне һәм аларның калдыкларын, зарарлы һәм агулы матдәләрне, җитештерү калдыкларын җир астына санкциясез күмүне һәм агып тәшүче суларны, шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләр булганнарын да, агызып чыгаруны, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын башкаручы органнар белән берлектә, чикләргә, туктатып торырга яисә тыярга;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне алып баручы оешмаларның җитәкчеләре алдына җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, куллану һәм саклау эшләрен башкаруның законнарда билгеләнгән тәртибен бозуда гаепле затларын җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне куярга һәм кирәк очракларда мондый затларны административ яисә җинаять җаваплылыгына тарту турындагы мәсьәләне карау өчен материалларны тиешле органнарга җибәрергә;

җир асты байлыклары турындагы законнарны бозу аркасында китерелгән зыянны түләттерү хакындагы дәгъвалар белән судка мөрәҗәгать итәргә;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча республика һәм җирле бюджет акчалары исәбенә башкарылучы эшләрне финанслауны (кредитлауны) туктату турындагы тәкъдимнәрне кирәк очракларда тиешле органнарга кертергә;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясенең гамәлдә булуын туктатып тору турында лицензия биргән органга тәкъдимнәр кертергә.

Дәүләти геологик тикшереп тору органы түбәндәгеләрне тикшерергә тиеш:

җир асты байлыкларын өйрәнгәндә һәм эшкәрткәндә уздырылучы геологик эшләрнең расланган проектларга һәм лицензия шартларына туры килүен;

геологик разведкалау циклының барлык стадияләрендә геологик тикшеренүләрнең нәтиҗәлелеген;

минераль чимал чыгаруның һәм аларны куллануның тулылыгын;

файдалы казылмалар ятмаларын су басулардан, янгыннардан

һәм файдалы казылмаларның сыйфатын, ятмаларның сәнәга әһәмиятен киметә яисә аларны эшкәртүне катлауландыра торган башка факторлардан саклау гамәлләренең нәтиҗәлелеген;

җир асты байлыкларын пычратмый торган системаларның ышанычлылыгын, бигрәк тә нефтьне, газны һәм башка матдәләрне, материалларны җир астында саклаганда, радиоактив, зарарлы һәм агулы матдәләрне, җитештерү калдыкларын күмгәндә, агып төшүче суларны агызып чыгарганда (шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләр булганнарын да ), торба үткәргечләр һәм башка корылмалар төзегәндә.

Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны дәүләти геологик тикшереп тору органы законнарда билгеләнгән башка вәкаләтләрне дә гамәлгә ашырырга хокуклы.

95 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне дәүләт тарафыннан җайга салу

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне дәүләт тарафыннан җайга салуга түбәндәгеләр керә:

җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең дәүләт программаларын әзерләү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылмаларны разведкалау өлкәсендә стандартларны, нормаларны һәм кагыйдәләрне билгеләү;

геологик тикшеренүләрнең төрле төрләрен оештыру;

җир асты байлыкларыннан файдалану тәртибенең, геологик өйрәнү барышында нормаларның, кагыйдәләрнең һәм стандартларның үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен исәпкә һәм дәүләт теркәвенә алу тәртибен билгеләү;

минераль чималга кондицияләр раслау;

файдалы казылмаларның запасларын һәм аларның ятмаларын дәүләт тарафыннан экспертизалауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

геологик мәгълүмат фондын оештыру һәм алып бару;

җир асты байлыклары турында мәгълүмат җыю, аны саклау һәм системалаштыру;

дәүләт бюджеты акчалары исәбенә алынган геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгеләү;

геологик мәгълүмат бирү һәм аннан файдалану тәртибен һәм аның буенча алыш-биреш гамәлләре кылуны хокукый җайга салу;

файдалы казылмалар ятмаларының һәм алар яткан урыннарның дәүләт кадастрын, шулай ук файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансын төзү тәртибен билгеләү;

169

геологик өйрәнү максатларында җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү.

96 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану аудиты

Җир асты байлыкларыннан файдалану аудиты җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, куллану һәм саклау белән бәйле эшчәнлегенең җир асты байлыкларыннан файдалану лицензияләре шартларына, җир асты байлыклары турындагы законнарга һәм бүтән норматив актларга туры килүен тикшерү максатларында гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга аудитор тикшерүләре барышында түбәндәгеләр ачыклана:

файдалы казылмаларның җир куенында һәм аларны беренчел эшкәрткәндә арттырылучы, аннан чыгарылучы, шунда югалып калучы запасларының микъдарын исәпкә алуның дөреслеге;

эшләрне алып баруда кулланылучы технологиянең файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең расланган технологияләренә туры килүе;

җир асты байлыкларыннан файдаланганда салымнарны һәм түләүләрне исәпләп чыгару өчен башлангыч белешмәләрнең дөреслеге һәм аларның чыгарылган, реализацияләнгән минераль чимал күләмнәренә туры килүе;

эшләрнең күләмнәре һәм төрләре, объектларны үзләштерү вакытлары, җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау таләпләрен үтәү өлешендә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану лицензияләрендәге шартларны һәм җир асты байлыкларыннан файдалануның башка нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү.

Җир асты байлыкларыннан файдалану аудиты законнарда билгеләнгән тәртиптә аттестация узган махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан башкарыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга аудитор тикшерүе җир асты байлыкларыннан файдаланучылар инициативасы буенча даими рәвештә уздырыла. Җир асты байлыкларыннан файдалануга мәҗбүри аудитор тикшерүләре җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясен биргән органнар карары белән гамәлгә ашырыла.

97 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып баруны дәүләт тарафыннан күзәтү

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып баруны дәүләт тарафыннан күзәтү бурычы эшләрне хәвеф-

сез башкару буенча, аларның халыкка, әйләнә-тирә табигать мохитенә, биналарга һәм корылмаларга тискәре йогынтысын булдырмау һәм бетерү буенча, шулай ук җир асты байлыкларын саклау буенча законнарда билгеләнгән стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) җир асты байлыкларыннан барлык файдаланучыларның үтәүләрен тәэмин итүдән гыйбарәт.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып баруны дәүләт тарафыннан күзәтүне (тау эшләрен күзәтү) шуңа вәкаләтле органнар башкара.

Тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органнары компетенциясе, хокуклары, вазыйфалары һәм аларның эш тәртибе законнар белән билгеләнә.

## X бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең хәвефсезлеге

### 98 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып баруны тәэмин итү

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне уздыру, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалы казылмалар чыгару һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шушы предприятиеләр хезмәткәрләренең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр алып бару зонасындагы халыкның гомеренә хәвефсезлек янамау һәм аларның сәламәтлеген саклау тәэмин ителгәндә генә рөхсәт ителә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларның (нормаларның, кагыйдәләрнең) таләпләрен үтәргә тиеш.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең хәвефсез шартларын тәэмин итү өчен турыдан-туры җаваплылык предприятиеләр җитәкчеләренә йөкләнә, бу предприятиеләр әлеге эшне үзләренә бирелгән лицензияләр нигезендә алып баралармы-юкмы яисә шартнамә буенча эшләр башкаруга җәлеп ителгәннәрме-юкмы, барыбер җаваплылык аларга йөкләнә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар, җитештерүдәге хәвефле хәлләрне һәм һәлакәтләрне алдан күреп, аларны булдырмауны һәм бетерүне, шул исәптән нефть һәм газның ачык фонтаннарын ябуны тәэмин итәргә тиеш.

Тау асты эшләрен алып баручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга тау эшләре буенча профессиональ коткару хезмәтләре тарафыннан хезмәт күрсәтелә, ә нефть һәм газ ятмаларын разведкалаганда һәм эшкәрткәндә бораулау эшләрен алып баручыларга нефть һәм газның ачык фонтаннарын булдырмау һәм бетерү

буенча профессиональ хезмәтләр тарафыннан аларның җир асты байлыкларыннан файдаланучылар белән төзегән шартнамәләре нигезендә хезмәт күрсәтелә.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне алып баручы тау эшләре предприятиеләре җитәкчеләре, шуңа вәкаләтле урындагы башка затлар, бу предприятиеләрнең хезмәткәрләре гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда, эшләрне кичекмәстән туктатып торырга һәм кешеләрне куркынычсыз урынга транспортта күчерүне тәэмин итәргә тиешләр, ә җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр йогынтысы зонасында яшәүче халыкның гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда, бу хакта дәүләт идарәсенең тиешле органнарына һәм җирле үзидарә органнарына кичекмәстән хәбәр итәргә тиешләр.

Җирле администрация, шулай ук, милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан, башка оешмалар, файдалы казылмалар чыгаручы предприятиеләрдә һәлакәтләр килеп чыккан очракларда, аларны транспорт, материаллар, җайланмалар, элемтә чаралары, медикаментлар белән тәэмин итәргә һәм һәлакәтне бетерү өчен башка төрле ярдәм күрсәтергә, шулай ук гадәттән тыш хәлләр турында Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән гамәлләрне башкарырга тиешләр.

**99 статья.** Эшләрне хәвефсез алып баруны тәэмин итү буенча төп таләпләр

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне хәвефсез алып баруны тәэмин итү буенча төп таләпләргә түбәндәгеләр керә:

эшкә махсус әзерлеге һәм квалификациясе булган затларны кабул итү, ә тау эшләренә җитәкчелек итү эшләренә - тиешле махсус белеме булган затларны кабул итү;

тау эшләрендә һәм бораулау эшләрендә мәшгуль затларны индивидуаль һәм коллектив яклау чаралары белән тәэмин итү;

хәвефсезлекнең тиешле кагыйдәләренә һәм санитар нормаларга туры килерлек машиналар, җайланмалар һәм материаллар куллану;

шартлаткыч матдәләрне һәм шартлату чараларын дөрес куллану, аларны тиешле рәвештә исәпкә алу, саклау һәм файдалану;

кагыйдәләргә һәм нормаларга нигезләнеп, җитештерү процессының нормаль барышын тикшереп тору һәм хәвефле хәлләр килеп чыгуны фаразлау өчен җитәрлек итеп, системалы күзәтүләр комплексын уздыру;

җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр алып ба-

ручы предприятиеләрнең хезмәткәрләрен һәм әлеге эшләр йогынтысы зонасында яшәүче халыкны гадәти режимда да һәм һәлакәткә китерерлек хәлләр килеп чыкканда да бу эшләрнең зарарлы йогынтысыннан саклауны тәэмин итүче гамәлләр әзерләү һәм уздыру.

### XI бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле бәхәсләрне хәл итү һәм җир асты байлыклары турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

100 статья. Бәхәсләрне хәл итү һәм шикаятьләрне карау тәртибе

Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү, шулай ук дәүләт органнарының гамәлләренә карата шикаятьләрне карау суд тарафыннан башкарыла.

101 статья. Җир асты байлыклары турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Җир асты байлыклары турындагы законнарны бозуда гаепле затлар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

102 статья. Зыянны түләттерү

Җир асты байлыклары турындагы законнарны бозып китерелгән зыян законнар нигезендә түләтелә.

### ХП бүлек. Халыкара шартнамәләр

107 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасы катнашкан халыкара шартнамәдә җир асты байлыклары турындагы Татарстан Республикасы законнарындагыдан бүтәнрәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла".

2 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында

1. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәте:

173

Хөкүмәтнең гамәлдәге актларына әлеге Законны кабул итүгә бәйле үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә;

әлеге Законны гамәлгә ашыру өчен кирәкле үз норматив хокукый актларын кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
N 2486